**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Ильбухтино авыл җирлеге составына керүче Кече Шилнә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

23 ноябрь, 2021ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Ильбухтино авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Ильбухтино авылында юлларны ремонтлау;
2) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау
3) су челтәрләрен ремонтлау (ремонт эшләре, проект эшләре)

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **512** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **260** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **259** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **1** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Ильбухтино авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Ильбухтиноавылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Ильбухтиноавылында юлларны ремонтлау;

2) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау

3) су челтәрләрен ремонтлау (ремонт эшләре, проект эшләре)

3. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Ильбухтино авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Ильбухтино авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы А.Г.Даутов